ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28 03 2022 г. № 162

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын күрсәтү турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарына өстәмә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын күрсәтү турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле текст өстәргә:

«2022 елның 1 мартыннан билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеседе хезмәткәре-ата-анага (әлеге вазыйфада 1 тулы ставкага эшләүче кече тәрбияче).»;

карарга кушымтада:

1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«-Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе хезмәткәре-ата-анага (әлеге вазыйфада 1 тулы ставкага эшләүче кече тәрбияче).»;

2.1 пунктның дүртенче абзацында «кладовщик» сүзеннән соң «, кече тәрбияче» сүзләрен өстәргә;

2.6 пунктның икенче абзацында «азык-төлек блогы» сүзеннән соң «, кече тәрбияче» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын күрсәтү турында» 2016 елның 4 маендагы 874 номерлы карарына һәм Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 маендагы 323 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Г. Мәхмүтовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Х. Муллин

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874